| СОВЕТ КУГУНУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУНЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
|---|---|
| «25» июня 2025 г. | № 130 |

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 02.11.2023 ел, №517-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге Советы:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге Советының 15.11.2010 №10 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге башкарма комитеты турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә::

1.1. 3.2.28 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3.2.28. балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;».

1.2. 5.6 пунктның 10 абзацы. түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "- Россия Федерациясе гражданлыгын йә чит дәүләт гражданлыгын туктату - чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының чит дәүләт гражданлыгы (гражданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының йә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукынраслый торган башка документы булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;".

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы" интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (baltasi.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Куныр авыл җирлеге башлыгы Р.О.Егоров